Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге Советы

Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

17 ноябрь, 2022 ел № 5

«Интернет челтәрендә урнаштырыла торган җирле үзидарә органы эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеген раслау хакында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгының 2016 елның 9 июнендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **карар бирәм**:

1. «Интернет челтәрендә урнаштырыла торган җирле үзидарә органы эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеген раслау хакында» 2016 елның 9 июнендәге 2 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- исемендә һәм алга таба текст буенча «Интернет челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Карар 2022 елның 1 декабреннән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Ленино-Кокушкино авыл җирлеге башлыгы А.Р.Сәйфетдинов